**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Петровский поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**16 октябрь 2023 ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Петровский поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Петровский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге поселок эчендәге юлларны ремонтлау (юл япмасын күтәрү, сатып алу, ташу, вак таш салу, транспорт хезмәтләре) шул исәптән поселок эчендәге юлларны сезонлы карап тоту;

Роторлы чапкыч сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова